**11 нче сыйныф**
**1 нче вариант**

**А1. Сүзнең дөрес язылган вариантын билгеләгез. (2 балл)**
1) сәләм
2) **сәлам**
3) саләм
4) салям

**А2.** ***Сөйләдеме*** **сүзендә басым төшкән иҗекне күрсәтегез. (2 балл)**
1) беренче
2) икенче
3) **өченче**
4) дүртенче

**А3.** ***Әниемне*** **сүзенең иҗекләргә дөрес аерылган вариантын билгеләгез. (2 балл)**
1) **әни-ем-не**
2) ә-ни-ем-не
3) әни-е-м-не
4) ә-ни-е-м-не

**А4.** ***Дөньяны аклыкка күмеп кар ява*** **җөмләсендәге** ***кар*** **сүзенең лексик мәгънәсен аңлатыгыз. (2 балл)**
1) тамыр сүз
2) уртаклык исем, баш килештә, тартым белән төрләнмәгән
3) **явым-төшемнең бер төре**
4) җөмләдә ия булып килә

**А5. Җыйма исемне табыгыз. (2 балл)**
1) **күрше-күлән**
2) күршесез
3) яңгырлы
4) яңгыравык

**А6. Хаталы сүзне табыгыз. (3 балл)**
1) моңлы
2) **төңге**
3) соңгы
4) сөңге

**A7. *Тормыш* сүзенең синонимын табыгыз. (3 балл)**
1) мәшәкать
2) көндәлек
3) хуҗалык
4) **хәят**

**A8. *Зарарлы* сүзенең антонимын табыгыз. (3 балл)**
1) зыянлы
2) кыен
3) **файдалы**
4) кирәкле

**A9. *Чыбык очы* фразеологизмының эквивалентын табыгыз. (3 балл)**
1) палка о двух концах
2) перегнуть палку
3) **седьмая вода на киселе**
4) за семью замками

**A10. Мәгънәле кисәкләргә таркатып булмаган сүзләр рәтен билгеләгез. (3 балл)**
1) кышын, тагын
2) **кавын, табын**
3) көзән, көзен
4) тезен, төзен

**A11. Рәвеш ясагыч кушымчалар кайсы төркемдә? (3 балл)**
1) -лык/-лек, -чан/-чән
2) -лан/-лән, -ла/-лә
3) **-лата/-ләтә, -ын/-ен**
4) -лы/-ле, -лай/-ләй

**A12. Билгеләү алмашлыгын күрсәтегез. (3 балл)**
1) һичбер
2) кайбер
3) **һәркайсы**
4) һичвакыт

**A13. Парлы сүзнең икенче компонентын табыгыз. *Килеш* – ...  (3 балл)**
1) чыгыш
2) чыгу
3) **килбәт**

4) килү

**А14.** ***Тиз-тиз кайту*** **– нинди сүзтезмә? (3 балл)**
1) сыйфатлы фигыль
2) сыйфатлы исем
3) **рәвешле фигыль**
4) рәвешле исем

**А15.** ***Сүзнең иң кадерлесе – әйтелми калганы*** **(Ә. Гаффар) мисалында җөмләнең төрен билгеләгез. (3 балл)**
1) **гади җөмлә**
2) тезмә кушма җөмлә
3) иярчен аныклагыч җөмлә
4) катлаулы кушма җөмлә

**В1. Лексикологиянең сүз мәгънәләрен өйрәнү белән шөгыльләнә торган тармагы ... дип атала. (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): СЕМАСИОЛОГИЯ**

**В2.** ***Китап чәчәк кебек <...> иркәләгәнне, назлаганны, ягъни укыганны ярата*** **(М. Госманов) җөмләсендә <...> тамгасы урынына нинди тыныш билгесе куелырга тиешлеген языгыз. (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән буш аралык калдырмыйча языгыз.**

**Җавап (Ответ): ИКЕНОКТА**

**В3. Күп кешенең сөйләшүе формасында бирелгән туры сөйләм … дип атала. (4 балл)**

**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): ПОЛИЛОГ**

**В4.** ***Шаять, бәлкем, мөгаен*** **кайсы сүз төркеменә керәләр? (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): КЕРЕШСҮЗ**

**В5. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. (4 балл)**

1) шигарь
2) мөлаем
3) сельдь
4) сердәш

А) 6 хәреф, 4 аваз
Б) 6 хәреф, 5 аваз
В) 6 хәреф, 6 аваз
Г) 6 хәреф, 7 аваз

**Хәрефләр җыелмасын баш хәрефләр белән буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): БГАВ**

**В6. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. (4 балл)**

1) көчле
2) күңел
3) мәкалә
4) шәһәр

А) язу
Б) егете
В) тынычлыгы
Г) җил

**Хәрефләр җыелмасын баш хәрефләр белән буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): ГВАБ**

**В7. *Һ, ы, м, л, и, н, а, б, р, е* хәрефләреннән сүз төзеп языгыз. (4 балл)**
**Хәрефләр җыелмасын баш хәрефләр белән буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): МИҺЕРБАНЛЫ**

**В8. Үзара бәйләнгән ике җөмлә тигез хокуклы булмаган очракта ... кушма җөмлә барлыкка килә. (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): ИЯРЧЕНЛЕ**

**В9. *Минһаҗ тәмам йокысы туеп уянганда, нарат исе АҢКЫП ТОРГАН өйдә беркем дә юк иде инде.* (М. Шәрифуллин) мисалында аерып бирелгән сүз җөмләнең кайсы кисәге була? (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): ХӘБӘР**

**В10. *Күз курка, … эшли* мәкалендә төшеп калган сүзне языгыз. (4 балл)**

**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): КУЛ**

**В11. Информация сүзенең тәрҗемәсен языгыз. (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): МӘГЪЛҮМАТ**

**В12. Тексттан атау җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Өянкенең дә бала чагы, үткәне була. 2) Кәүсәсенә еллар боҗрасы өстәлгән саен, аның хәтере дә байый баруын кешеләр беләләр микән? 3) Ул, яшел кабыклы нәзек тал булып, дөньяга беренче тапкыр күзен ачканда, авыл урамыннан, тузан туздырып, җигүле атларда бүтән гасыр кешеләре уза иде әле. 4) Аның иң беренче теләге бакча читәне аша үрелеп карау булды, әмма буе җитмәде. 5) Кыска буйлы тал-тирәк ихата эчен күзәтә башлады. 6) Янәшәдә генә – сиртмәле кое. 7) Арырак – салам түбәле өй. 8) Кое сиртмәсе, шыгырдап, бер төшә, бер күтәрелә. 9) Янәшәдә генә салкын җир дымын, шифалы су тәмен тою тал-чыбыкка рәхәтлек бирә. 10) Аның тизрәк үсәсе, ак болытларга ябалдашы белән орынасы килә. (М. Галиев)
**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 67**

**В13. Тексттан аерымланган хәлләр кулланылган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Өянкенең дә бала чагы, үткәне була. 2) Кәүсәсенә еллар боҗрасы өстәлгән саен, аның хәтере дә байый баруын кешеләр беләләр микән? 3) Ул, яшел кабыклы нәзек тал булып, дөньяга беренче тапкыр күзен ачканда, авыл урамыннан, тузан туздырып, җигүле атларда бүтән гасыр кешеләре уза иде әле. 4) Аның иң беренче теләге бакча читәне аша үрелеп карау булды, әмма буе җитмәде. 5) Кыска буйлы тал-тирәк ихата эчен күзәтә башлады. 6) Янәшәдә генә – сиртмәле кое. 7) Арырак – салам түбәле өй. 8) Кое сиртмәсе, шыгырдап, бер төшә, бер күтәрелә. 9) Янәшәдә генә салкын җир дымын, шифалы су тәмен тою тал-чыбыкка рәхәтлек бирә. 10) Аның тизрәк үсәсе, ак болытларга ябалдашы белән орынасы килә. (М. Галиев)
**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 38**

**B14. Тексттан тиңдәш кисәкләр кулланылган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Өянкенең дә бала чагы, үткәне була. 2) Кәүсәсенә еллар бөҗрасы өстәлгән саен, аның хәтере дә байый баруын кешеләр беләләр микән? 3) Ул, яшел кабыклы нәзек тал булып, дөньяга беренче тапкыр күзен ачканда, авыл урамыннан, тузан туздырып, җигүле атларда бүтән гасыр кешеләре уза иде әле. 4) Аның иң беренче теләге бакча читәне аша үрелеп карау булды, әмма буе җитмәде. 5) Кыска буйлы тал-тирәк ихата эчен күзәтә башлады. 6) Янәшәдә генә – сиртмәле кое. 7) Арырак – салам түбәле өй. 8) Кое сиртмәсе, шыгырдап, бер төшә, бер күтәрелә. 9) Янәшәдә генә салкын җир дымын, шифалы су тәмен тою тал-чыбыкка рәхәтлек бирә. 10) Аның тизрәк үсәсе, ак болытларга ябалдашы белән орынасы килә. (М. Галиев)
**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 138910**

**B15. Тексттан кушма җөмләләрне табыгыз һәм аларның санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Өянкенең дә бала чагы, үткәне була. 2) Кәүсәсенә еллар бөҗрасы өстәлгән саен, аның хәтере дә байый баруын кешеләр беләләр микән? 3) Ул, яшел кабыклы нәзек тал булып, дөньяга беренче тапкыр күзен ачканда, авыл урамыннан, тузан туздырып, җигүле атларда бүтән гасыр кешеләре уза иде әле. 4) Аның иң беренче теләге бакча читәне аша үрелеп карау булды, әмма буе җитмәде. 5) Кыска буйлы тал-тирәк ихата эчен күзәтә башлады. 6) Янәшәдә генә – сиртмәле кое. 7) Арырак – салам түбәле өй. 8) Кое сиртмәсе, шыгырдап, бер төшә, бер күтәрелә. 9) Янәшәдә генә салкын җир дымын, шифалы су тәмен тою тал-чыбыкка рәхәтлек бирә. 10) Аның тизрәк үсәсе, ак болытларга ябалдашы белән орынасы килә. (М. Галиев)
**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 234**

**11 нче сыйныф**
**2 нче вариант**

**А1. Сүзнең дөрес язылган вариантын билгеләгез. (2 балл)**
1) сәләмәт
2) саләмат
3) саләмәт
4) **сәламәт**

**А2.** ***Сөйләшмәгез*** **сүзендә басым төшкән иҗекне күрсәтегез. (2 балл)**
1) беренче
2) **икенче**
3) өченче
4) дүртенче

**А3.** ***Әтиемне*** **сүзенең иҗекләргә дөрес аерылган вариантын билгеләгез. (2 балл)**
1) **әти-ем-не**
2) ә-ти-ем-не
3) әти-е-м-не
4) ә-ти-е-м-не

**А4.** ***Адәм баласының да сабыр итүенең бер чиге бар*** **(М. Мәһдиев) җөмләсендәге** ***сабыр*** **сүзенең лексик мәгънәсен аңлатыгыз. (2 балл)**
1) тамыр сүз
2) **түзем һәм тыныч, ашыкмаучан**
3) сыйфат, төп юнәлештә
4) җөмләдә аергыч булып килә

**А5. Җыйма исемне табыгыз. (2 балл)**
1) **каз-үрдәк**
2) кайгыртучанлык
3) бозлавык
4) таш

**А6. Хаталы сүзне табыгыз. (3 балл)**
1) яңгыр
2) бәрәңге
3) соңгы
4) **иртәңге**

**А7.** ***Хәтфә*** **сүзенең синонимын табыгыз. (3 балл)**
1) хәтер
2) хәтсез
3) бәхет
4) **бәрхет**

**А8.** ***Еш*** **сүзенең антонимын табыгыз. (3 балл)**
1) **сирәк**
2) ерак
3) якын
4) кереш

**А9.** ***Йөзгә кызыллык китермәү*** **фразеологизмының эквивалентын табыгыз. (3 балл)**
1) на нем лица нет
2) на лицо красивый
3) **не ударить лицом в грязь**
4) бумага не краснеет

**А10. Мәгънәле кисәкләргә таркатып булган сүзләр рәтен билгеләгез. (3 балл)**
1) чиләк, җиләк
2) калак, кирәк
3) **көрәк, тарак**
4) йозак, тозак

**А11. Рәвеш ясагыч кушымчалар кайсы төркемдә? (3 балл)**
1) -лы/-ле, -сыз/-сез
2) -лан/-лән, -ла/-лә
3) -даш/-дәш, -чык/-чек
4) **-лап/-ләп, -лай/-ләй**

**А12. Билгеләү алмашлыгын күрсәтегез. (3 балл)**
1) шул
2) **бөтен**
3) кемдер
4) берничек

**А13. Парлы сүзнең икенче компонентын табыгыз.** *Дус* – … **(3 балл)**
1) дуслык
2) дуслашу

3) **иш**
4) ишкәк

**А14.** ***Матур сөйләү*** **– нинди сүзтезмә? (3 балл)**
1) **сыйфатлы фигыль**
2) сыйфатлы исем
3) рәвешле хәбәрлек сүз
4) рәвешле исем

**А15.** ***Җырның сере, көче нәрсәдә соң?*** **мисалында җөмләнең төрен билгеләгез. (3 балл)**
1) **гади җөмлә**
2) тезмә кушма җөмлә
3) иярчен хәбәр җөмлә
4) тезем

**В1. Дөрес әйтү нормалары һәм кагыйдәләре җыелмасы ... дип атала. (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): ОРФОЭПИЯ**

**В2.** ***Аңлашыла ки <...> бу мәсьәлә җиңел түгел*** **җөмләсендә <...> тамгасы урынына нинди тыныш билгесе куелырга тиешлеген языгыз. (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән буш аралык калдырмыйча языгыз.**

**Җавап (Ответ): ӨТЕР**

**В3. Ике кешенең үзара сөйләшүе формасында бирелгән туры сөйләм … дип атала. (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): ДИАЛОГ**

**В4.** ***Фәкать, я, гүя*** **кайсы сүз төркеменә керәләр? (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): ТЕРКӘГЕЧ**

**В5. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. (4 балл)**

| | |
|---|---|
| 1) ямьле | А) 5 хәреф, 6 аваз |
| 2) юлдаш | Б) 5 хәреф, 5 аваз |
| 3) сәгать | В) 4 хәреф, 5 аваз |
| 4) җәен | Г) 6 хәреф, 5 аваз |

**Хәрефләр җыелмасын баш хәрефләр белән буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): БАГВ**

**В6. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. (4 балл)**

| | |
|---|---|
| 1) югары | А) халкы |
| 2) тәртипле | Б) әйтү |
| 3) хәбәр | В) сыйфатлы |
| 4) ил | Г) бала |

**Хәрефләр җыелмасын баш хәрефләр белән буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): ВГБА**

**В7. *Е, ш, к, ә, т, а, ф, ь, л* хәрефләреннән сүз төзеп языгыз. (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): ШӘФКАТЬЛЕ**

**В8. Үзара бәйләнгән ике җөмлә тигез хокуклы булган очракта ... кушма җөмлә барлыкка килә. (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): ТЕЗМӘ**

**В9. *Туган илдән КИТКӘН сандугачлар чит җирләрдә сайрый алмыйлар* (И. Юзеев) мисалында аерып бирелгән сүз җөмләнең кайсы кисәге була? (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): АЕРГЫЧ**

**В10. … *таулар күчерә* мәкалендә төшеп калган сүзне языгыз. (4 балл)**

**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): ДУСЛЫК**

**B11. Искусство сүзенең тәрҗемәсен языгыз. (4 балл)**
**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**Җавап (Ответ): СӘНГАТЬ**

**B12. Тексттан кире сүз тәртибендәге җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Сугыш бетеп, бер ел үткәч, Алтын Болак авылы кешеләре матур бер гадәт уйлап чыгарды. 2) Хатын-кызлар, яудан кайткан ир-атлар Җиңү көнендә Өянке янына җыела. 3) Шушыннан киткәннәр бит алар, шушыннан озатып калганнар бит аларны… 4) Ирләре һәлак булган хатыннар, эчке бер өмет белән, үзләре чиккән кулъяулыкларны Өянке ботакларына элделәр. 5) Алардан соң, вәгъдәләр куешкан егетләре кайтмый калган кызлар, кулъяулык тотып, Өянке янына килделәр. 6) Күзләр яшьләнде. 7) Китте хатирәләр. 8) Авылдан чыгып киткән йөз унике ир-егет кире әйләнеп кайтмады. 9) Ә Өянке ботакларында алар истәлегенә төрле җепләр белән чигелгән йөз унбер кулъяулык җилферди... (М. Галиев)

**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 37**

**B13. Тексттан җыйнак җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Сугыш бетеп, бер ел үткәч, Алтын Болак авылы кешеләре матур бер гадәт уйлап чыгарды. 2) Хатын-кызлар, яудан кайткан ир-атлар Җиңү көнендә Өянке янына җыела. 3) Шушыннан киткәннәр бит алар, шушыннан озатып калганнар бит аларны… 4) Ирләре һәлак булган хатыннар, эчке бер өмет белән, үзләре чиккән кулъяулыкларны Өянке ботакларына элделәр. 5) Алардан соң, вәгъдәләр куешкан егетләре кайтмый калган кызлар, кулъяулык тотып, Өянке янына килделәр. 6) Күзләр яшьләнде. 7) Китте хатирәләр. 8) Авылдан чыгып киткән йөз унике ир-егет кире әйләнеп кайтмады. 9) Ә Өянке ботакларында алар истәлегенә төрле җепләр белән чигелгән йөз унбер кулъяулык җилферди... (М. Галиев)

**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 67**

**B14. Тексттан аерымланган хәлләр кулланылган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Сугыш бетеп, бер ел үткәч, Алтын Болак авылы кешеләре матур бер гадәт уйлап чыгарды. 2) Хатын-кызлар, яудан кайткан ир-атлар Җиңү көнендә Өянке янына җыела. 3) Шушыннан киткәннәр бит алар, шушыннан озатып калганнар бит аларны… 4) Ирләре һәлак булган хатыннар, эчке бер өмет белән, үзләре чиккән кулъяулыкларны Өянке ботакларына элделәр. 5) Алардан соң, вәгъдәләр куешкан егетләре кайтмый калган кызлар, кулъяулык тотып, Өянке янына килделәр. 6) Күзләр яшьләнде. 7) Китте хатирәләр. 8) Авылдан чыгып киткән йөз унике ир-егет кире әйләнеп кайтмады. 9) Ә Өянке ботакларында алар истәлегенә төрле җепләр белән чигелгән йөз унбер кулъяулык җилферди... (М. Галиев)

**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 45**

**B15. Тексттан кушма җөмләләрне табыгыз һәм аларның санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (4 балл)**

1) Сугыш бетеп, бер ел үткәч, Алтын Болак авылы кешеләре матур бер гадәт уйлап чыгарды. 2) Хатын-кызлар, яудан кайткан ир-атлар Җиңү көнендә Өянке янына җыела. 3) Шушыннан киткәннәр бит алар, шушыннан озатып калганнар бит аларны… 4) Ирләре һәлак булган хатыннар, эчке бер өмет белән, үзләре чиккән кулъяулыкларны Өянке ботакларына элделәр. 5) Алардан соң, вәгъдәләр куешкан егетләре кайтмый калган кызлар, кулъяулык тотып, Өянке янына килделәр. 6) Күзләр яшьләнде. 7) Китте хатирәләр. 8) Авылдан чыгып киткән йөз унике ир-егет кире әйләнеп кайтмады. 9) Ә Өянке ботакларында алар истәлегенә төрле җепләр белән чигелгән йөз унбер кулъяулык җилферди... (М. Галиев)

**Саннар тезмәсен буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.**

**Җавап (Ответ): 1345**